ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МОНАШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423644 с.Монашево, ул.Школьная д.19

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МОНАШЕВО АВЫЛЫ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

423644, ТР, Менделеевск районы, Монашево
авылы, Мәктәп урамы 19 йорт

Тел.(885549)3-73-18 ИНН 1627005472, КПП162701001 ОКПО 93072831 ОГРН 1061674006570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

22.12.2023 ел №24

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
«Монашево авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге чикләрен туры китерү
мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар уздыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Монашево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлегендә яшәүчеләрнең «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чикләрен гавами тыңлаулар уздыру юлы белән туры китерү турындагы мәсьәлә буенча фикер алышуда катнашу хокукын үтәү максатларында,

Карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы чикләренә, Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Монашево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чиген туры китерү мәсьәләсе буенча 1 нче кушымта нигезендә гавами тыңлаулар уздырырга

2. Татарстан Республикасы, Менделеевск муниципаль районы, Монашево ав., Ленин ур., 18 йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасының актлар залын гавами тыңлаулар үткәрү урыны итеп билгеләргә. Үткәрү датасы һәм вакыты 30.01.2024 ел 17 сәгать 30 минутта

3. Менделеевск муниципаль районы Советының 2023 елның 18 декабрендәге 229 номерлы карарында билгеләнгән тәртип һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда түбәндәге составта күрсәтелгән инициативаны карау буенча гавами тыңлаулар оештыру һәм уздыру буенча эш төркеме төзергә:

- Иосифов Ростислав Феофанович -

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл

җирлеге башлыгы;

-Кузнецов Александр Анатольевич - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Монашево авыл җирлеге советы депутаты;

-Григорьева Наталия Сергеевна - ТР Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре.

4. Фикер алыша торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2024 елның 30 гыйнварына кадәр эш көннәрендә 9.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр хакимият бинасында түбәндәге адрес буенча кертелә: Монашево авылы, Монашево ур., Мәктәп 19 йорт, язма рәвештә авторның Ф.И.А адресы күрсәтеп электрон почтага: Mon.Men@tatar.ru.

5. Чыгыш хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә: 423644, ТР, Монашево авылы Менделеевск районы, Мәктәп урамы, 19 шәхси йорт яисә почта аша (“муниципаль берәмлекләр чикләрен үзгәртү турында фикер алышу” конвертында тамга белән) ТР Менделеевск муниципаль районы Советы карары белән расланган гавами тыңлауларны оештыру тәртибе нигезендә 2024 елның 30 гыйнварына кадәр.

6. Әлеге Карарны Монашево авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында,, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru “Монашево авыл җирлеге” бүлегендә урнаштырырга https://mendeleeevsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http//pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Монашево авыл җирлеге башлыгы Р.Ф. Иосифов

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлеге башлыгының .2023нче елның 22 нче декабрендәге 24 номерлы карарына кушымта

